ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 521-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

А.В. Тыгин тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен башкарган чорда кертелгән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 521-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2348-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1–2, № 10; Татарстан Республикасы Законнар җыелмасы, 2017, № 33, (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1, (часть I), № 29 (часть I); 2022, № 57 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 20 (часть I), № 73 (часть I) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 4 өлештә «$4^1$ өлешендә» сүзләрен «$4^1$ һәм $4^{1-1}$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^{1-1}$ өлеш өстәргә:

«$4^{1-1}$. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә тапшырылган һәм әлеге күпфатирлы йортның параметрлары үзгәрүгә бәйле үзгәрешләр бу программага кертелгәндә үзе турындагы белешмәләр анда чагылдырылган күпфатирлы йорт өлешендә урнашкан урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы әлеге өлештә күрсәтелгән белешмәләр чагылдырылган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килүче айдан башлап алты календарь ай үткәннән соң барлыкка килә. Күпфатирлы йортның күрсәтелгән өлешендә урнашкан урыннар милекчеләре, капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы барлыкка килгән датадан башлап, капиталь ремонт өчен кертемне күпфатирлы йортның күрсәтелгән өлешен эксплуатациягә тапшырган датага кадәр мондый күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын булдыру алымын билгеләү турындагы кабул ителгән һәм гамәлгә ашырылган карар, әгәр бу датадан соң мондый күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре тарафыннан башка карар кабул ителмәгән булса, нигезендә түлиләр.»;

в) $4^2$ өлештә «дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә» сүзләреннән соң «, яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә торак төзелеше

территориясен комплексны үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат милкенә,» сүзләрен өстәргә»;

2) 10 статьяның $10^3$ өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $4^{1-1}$ өлеше нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә тапшырылган һәм әлеге күпфатирлы йортның параметрлары үзгәрүгә бәйле үзгәрешләр бу программага кертелгәндә үзе турындагы белешмәләр анда чагылдырылган күпфатирлы йорт өлешендә урнашкан урыннар милекчеләренә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәрнең әлеге Закон үз көченә кергән көнгә артык саналган һәм күрсәтелгән урыннан милекчеләре тарафыннан түләнгән суммасы (урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәүгә бәйле рәвештә алар тарафыннан түләнгән пеняларны да кертеп) автомат рәвештә аларның киләчәк чорга капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен үтәү исәбенә санала.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – 52-ТРЗ номерлы Закон) федераль законнарга туры китерү максатыннан эшләнде.

«Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 декабрендәге 601-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Торак кодексына файдалануга этаплап тапшырыла торган күпфатирлы йортта (шул исәптән аерым секцияләре) милекчеләрнең гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәр түли башлау кагыйдәсе кертелде.

Әлеге үзгәрешләр нигезендә күпфатирлы йортларда капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә тапшырылган һәм әлеге күпфатирлы йортның параметрлары үзгәрүгә бәйле үзгәрешләр бу программага кертелгәндә үзе турындагы белешмәләр анда чагылдырылган күпфатирлы йорт өлешендә урнашкан урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү бурычы Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы билгеләгән срок үткәннән соң, ләкин капиталь ремонт буенча региональ программага әлеге үзгәрешләр кертелгән датадан алып биш елдан да артык булмаган вакытта барлыкка килә.

Закон проектында, урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәсе барлыкка килә торган срокны региональ программа рәсми басылып чыккан айдан соң килүче айдан башлап алты календарь ай дәвамында билгеләп, 52-ТРЗ номерлы Законга тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә. Әлеге нигезләмәләр республика законы гамәлгә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылачак.

Капиталь ремонт өчен түләүне кичектереп торуның тәкъдим ителгән срогы капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң файдалануга тапшырылган күпфатирлы йортларда урыннар милекчеләре өчен 52-ТРЗ номерлы Законның $4^1$ өлешендә билгеләнгән капиталь ремонт өчен түләү кертү срогына туры килә.

Закон проекты шулай ук «Россия Федерациясе Шәһәр кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 52-ТРЗ номерлы Законның 2 статьясындагы $4^2$ өлеше нигезләмәләрен төгәлләштерү тәкъдим ителә. Аңа торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү чикләрендә урнашкан күпфатирлы йортларда урыннарны, шул исәптән, юридик зат милкенә дә тапшыруны күздә тота торган үзгәреш кертелә.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының үз көчен югалтуны тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.